СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**«04» октябрь 2016 ел** **№25**

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 20 ноябренә Урта Курса авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2017 елда Урта Курса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

- Авылларда юлларны төзекләндерү (вак таш) җәю:
- Югары Курса ав.

А. Алиш ур., 8дән 11гә кадәр,
А. Алиш ур., 4дән 23кә кадәр Школьная ур.;
- Урта Курса ав.

Гагарин ур., 1 йорт, Тукай ур., 11 йорт;
- Сарай-Чокырча ав.

М. Җәлил ур., 8дән 16га кадәр;
- Түбән Курса ав.

Пушкин ур., 1а йорттан алып 27 йортка кадәр

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Урта Курса авылы, Яшьләр ур., 13, Урта Курса авылы, Сәйдәшев ур., 8) мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СРЕДНЕКОРСИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СОВЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609003070